КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 октябрь г.Казань № 897

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 17 июль, 499 нчы карары белән расланган Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук әлеге чараларда Татарстан Республикасы командалары катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук әлеге чараларда Татарстан Республикасы командалары катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 17 июль, 499 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 130 нчы; 2018 ел, 21 сентябрь, 811 нче, 2019 ел, 29 март, 238 нче, 2019 ел, 09 август, 649 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәгълүмат технологияләре, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника

өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чаралар оештыруга һәм үткәрүгә бәйле, шулай ук әлеге чараларда Татарстан Республикасы командалары катнашуын тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3. Субсидияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (алга таба – министрлык), тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак, билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә.»;

4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үзгәртеп кору, бетерү процессында тормыйлар, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, коммерциягә карамаган оешмалар эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылырга тиеш түгел.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешмалар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

субсидия алу өчен Министрлык тарафыннан расланган форма буенча гариза (алга таба – гариза) ;

коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турындагы документларның, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе яисә, тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәләрен кушып);

чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү очрагында - коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан расланган әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар сметасына ;

субсидияләр чыгымнарны каплауга бирелгән очракта - коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнарны гамәлгә ашыруга бәйле фактта тотылган чыгымнарын раслаучы документлар күчермәләре (чыгымнар сметасы, шартнамәләр һәм аларга кушымталар, башкарылган эшләр актлары (күрсәтелгән хезмәтләр), түләү йөкләмәләре, шулай ук (булган очракта) счет, счет-фактуралар, керем һәм чыгым ордерлары, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе яки башка вәкаләтле зат раслаган накладнойлар (тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда) Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәсен теркәп));

килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 көненә салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән вазыйфасының булмавынраслый торган белешмә;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хаты, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бурычларны һәм килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 көненә Татарстан Республикасы бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары булмау турында;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хаты, коммерциягә карамаган оешманың үзгәртеп кору, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен раслый, килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1 көненә коммерциягә карамаган оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау турында.

Коммерциягә карамаган оешма әлеге пунктның алтынчы абзацында каралган документ тапшырмаган очракта, Министрлык күрсәтелгән документны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

7 пунктның дүртенче абзацында «баш идарәче» сүзләрен «Министрлык» сүзенә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Коммерциячел булмаган оешмага субсидия бирүдән баш тартуы өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

коммерциягә карамаган тарафыннан бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 5 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең 4 һәм $4^1$ пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә һәм сайлап алу критерийларына туры килмәве.»;

10 пунктта:

бишенче абзацта «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләрне « сүзенә алмаштырырга»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«өстәмә хисап бирү сроклары һәм рәвешләре (кирәк булганда), әлеге Тәртиптә билгеләнгән форма буенча һәм срокларда субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирү турында йөкләмә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кирәк булганда, Министрлык субсидия алучылар белән килешүгә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма нигезендә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:

«$11^1$. Агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйле рәвештә субсидияләр бирү мөмкин булмаган очракта, субсидияләр чираттагы финанс елында әлеге Тәртипнең $4^1$ пунктында күрсәтелгән сайлап алу критерийларына туры килә торган субсидия

алучыга чираттагы финанс елында, сайлап алуның күрсәтелгән критерийларына туры килү-килмәүне кабат узмыйча, бюджет йөкләмәләренең тиешле лимитлары чикләрендә бирелә.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидияләр алучылар Министрлыкка субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыралар.»;

түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәргә:

«$15^1$. Субсидия бирү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

субсидияләр алучылар тарафыннан оештырылган һәм үткәрелгән мәгълүмати технологияләр, цифрлы икътисад һәм (яки) робототехника өлкәсендә семинарлар, конференцияләр, форумнар, олимпиадалар, интеллектуаль конкурслар һәм башка чараларда катнашучылар саны;

күрсәтелгән чараларда катнашучы иң яхшы командалар исемлегенә кергән Татарстан Республикасы командаларының өлеше.»;

17 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшырмаган очракта, шулай ук өстәмә хисап бирелмәгән очракта, әгәр килешүдә өстәмә хисап бирү каралган булса, тулы күләмдә;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән очракта, субсидия бирүнең һәр ирешелгән күрсәткеченә 5 процент күләмендә;»;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымта өстәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин